**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕГОРКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ЕГОРКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Егоркино ав. **БОЕРЫК**

09.12.2022 № 13

**Егоркино авыл җирлеге территориясендә 2023 елга наркотикларга каршы көрәш чаралары планын раслау турында**

Наркоманиянең таралу куркынычын киметү максатларында, “Наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә каршы тору буенча өстәмә чаралар турында" 18.10.2007 ел, № 1374 Россия Федерациясе Президенты Указына таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге территориясендә наркотикларга каршы чаралар планын расларга (1 нче кушымта).

2. Карарны мәгълүмат стендларында һәм «Интернет»челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Егоркино авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе А.И.Борисов

2022 елның «09» декабрендәге
Егоркино авыл җирлеге
башкарма комитеты
җитәкчесенең 13 нче номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге территориясендә 2023 елга наркотикларга каршы көрәш чаралары планы.**

| № т\с | Чаралар атамасы | Башкару вакыты | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Наркоманияне, токсикоманияне, алкоголизмны һәм тәмәке тартуны профилактикалау өлкәсендәге законнарны камилләштерү буенча норматив-хокукый актлар проектларын эшләү һәм эшләүдә катнашу | Ел дәвамында | Җитәкче урынбасары |
| 2. | Наркотик матдәләр булган үсемлекләрне законсыз үстергән өчен административ һәм җинаять җаваплылыгын аңлату максатыннан авыл җирлегенең торак пунктларында яшәүчеләр җыелышларын уздыру. | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 3 | Нурлат муниципаль районының наркотикларга каршы комиссиясе утырышларында катнашу | Таләп ителгәндә | Авыл җирлеге башлыгы |
| 4 | Җирлек территориясендә наркоманияне, токсикоманияне, алкоголизмны һәм тәмәке тартуны профилактикалау мәсьәләләре буенча белем бирү учреждениеләре белән хезмәттәшлек. | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе, мәгариф оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 5 | Егоркино авыл җирлеге буенча наркотик матдәләр куллануга сәләтле затларны ачыклау буенча уртак рейдларда катнашу. | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе, полиция участок уполномоченные (килешү буенча) |
| 6 | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча чаралар үткәрү. | Ел дәвамында | Авыл җирлеге администрациясе, авыл җирлегенең мәгариф һәм мәдәният оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 | Кешеләр күпләп була торган мәдәни-массакүләм, иҗтимагый-сәяси чаралар уздыру вакытында администрациянең җаваплы затларының, мәдәният хезмәткәрләренең дежур торуларын оештыру. | Ел дәвамында | Авыл җирлеге администрациясе, авыл җирлегенең мәдәни оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 8 | Хокук бозуга сәләтле (элек хөкем ителгән, шартлы рәвештә хөкем ителгән, шартлы рәвештә вакытыннан алда азат ителгән) исәптә торучы гражданнар арасында аңлату-профилактика эшләрен алып бару. | Ел дәвамында | Авыл җирлеге администрациясе, полиция участок полициясе (килешү буенча) |
| 9 | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, наркоманияне, токсикоманияне, алкоголизмны һәм тәмәке тартуны профилактикалау буенча мәгълүмат урнаштыру:<br>- җирлекнең рәсми сайтында;<br>- мәгълүмат стендларында; | Ел дәвамында | Җитәкче урынбасары |
| 10 | Җирлектә имин булмаган гаиләләр, яшьләр һәм балигъ булмаганнар белән профилактик эштә ярдәм күрсәтү | Ел дәвамында | Авыл җирлеге администрациясе, полиция участок полициясе (килешү буенча) |